РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 42 2023 елның 10 августы

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 11 ноябрендәге 62 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 11 ноябрендәге 62 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясенә кертелә торган үзгәрешләрне расларга (кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы Р.Х. Муллин

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

Түбән Кама муниципаль
районы Советының
2023 елның 10 августындагы
42 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 11 ноябрендәге 62 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясенә кертелә торган үзгәрешләр (алга таба – Стратегия)

1. Стратегиянең 4 бүлегендәге 4.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«2020-2022 елларга Республиканың Инвестицион меморандумы белән билгеләнгән Татарстан Республикасының инвестицион сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2022 елга өстенлекле инвестицион проектларның расланган исемлеге нигезендә, «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы аерым икътисади зонасы» АҖ региональ әһәмияттәге объектны - Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә «Этилен 600» индустриаль паркын гамәлгә ашыру чараларын башкара.

Инвестицион проектны гамәлгә ашыру урыны «ИнноКам» территориаль аерымланган инновацион-җитештерү үзәген үстерү кысаларында белем бирү һәм фәнни учреждениеләр белән өстәмә тәэмин итү мөмкинлеге белән, нефть химиясе, нефть эшкәртү, автомобиль төзелеше, автокомпонентлар җитештерү өлкәсендәге предприятиеләрне бердәм технологик кластерга берләштерү максатында билгеләнгән.

Шуңа бәйле рәвештә Түбән Кама сәнәгать узелы чикләрендә сәнәгать җитештерүләрен үстерү һәм гамәлдәге производстволарда технологияләрне модернизацияләү өчен инвестицион проект белән түбәндәге объектларны урнаштыру тәкъдим ителә:

1. Лаборатория-конструкторлык комплексы.

Максат: «Этилен 600» индустриаль паркы резидентларын кадрлар белән тәэмин итү өчен квалификацияле белгечләрне укыту процессын оештыру.

Укыту түбәндәге юнәлешләр буенча алып барылачак:

- мехатроника һәм робототехника (интеллектуаль машиналар, физик-техник системалар һәм төрле билгеләнештәге процесслар булдыру);
- сәнәгать автоматикасы (җитештерүне автоматлаштыру) химик анализ лаборанты (химик матдәләрнең сыйфат һәм сан характеристикаларын билгеләү максатыннан, лаборатория анализлары, сынаулар, үлчәүләр башкару);
- химия технологиясе (химик җитештерүдә технологик процессларны оештыру, аларны модификацияләү, шулай ук предприятиеләрдә сыйфатлы продукция җитештерү өчен яңа алгоритмнар эшләү);
- органик һәм биоорганик химия (булган һәм яңа органик кушылмаларны синтезлау, органик синтез продуктларын практик куллану максатында, синтезланган кушылмаларның химик үзлекләрен бәяләү);
- химия технологиясендә, нефть химиясендә һәм биотехнологиядә энергия һәм ресурсларны саклый торган процесслар (нефть-газ комплексы предприятиеләре өчен химик кушылмалар җитештерү технологияләрен эшләү, химик кушылмаларның киң номенклатурасы җитештерүләрен оптимальләштерү - ашханә техникасы, текстиль, компьютерлар, шулай ук югары технологияле продукция);
- электротехника (төрле энергия төрләрен алу һәм үзгәртү процессы, электр һәм магнит күренешләрен кулланып, мәгълүмати сигналларны тапшыру һәм кабул итү).

1.1. – 1.15. комплекс объектларын урнаштыру 16:30:011801 кадастр кварталы чикләрендә урман фонды җирләре составындагы җир кишәрлекләрендә якынча 730 га мәйданда планлаштырыла.

Лаборатория-конструкторлык комплексы составына түбәндәге объектлар керә:

1.1. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 45 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2026 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 139 000 кв. м.

1.2. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 46 нчы корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2026 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 84 000 кв. м.

1.3. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 44 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 59 000 кв. м.

1.4. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 47 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 59 000 кв. м.

1.5. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 48 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 68 000 кв. м.

1.6. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 49 нчы корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру -2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 70 000 кв. м.

1.7. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 50 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы -70 000 кв. м.

1.8. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 51 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 58 000 кв. м.

1.9. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 52 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы -70 000 кв. м.

1.10. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 53 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 84 000 кв. м.

1.11. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 54 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 65 000 кв. м.

1.12. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 64 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 72 000 кв. м.

1.13. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 65 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 82 000 кв. м.

1.14. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 55 нче корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 59 000 кв. м.

1.15. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 56 нчы корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 38 000 кв. м.

1.16. «Синергия» индустриаль-технологик паркы. 56 нчы корпус. «Алабуга Политех «Органик химия».

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Объектның гомуми мәйданы - 40 000 кв. м.

Объектны 16:30:011402:77 кадастр номерлы җир кишәрлеге чикләрендә урнаштыру планлаштырыла.

2. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ җитештерүләре өчен логистик үзәк.

Файдалануга тапшыру – 2024 ел.

Максат: «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ продукциясен төяп җибәрү һәм транспортлау.

Логистика үзәген 16:53:030105:840 кадастр номерлы җир кишәрлегендә урнаштыру планлаштырыла.

3. Социаль-белем бирү кластеры объектлары - белгечләр кампуслары (7 корпус).

Файдалануга тапшыру – 2028 ел.

Максат: социаль инфраструктура булдыру юлы белән, ягъни һәр корпуста 1960 кв. м. гомуми мәйданлы беренче һәм икенче катларда җәмәгать урыннары (коворкинг, ашханә, спорт залы, ирекле коммерция мәйданнары һ.б.) булган торак зона (14 катлы җиде бина), «Этилен 600» индустриаль паркы резидентларының кадрлар потенциалын үстерү.

Объектларны 16:53:040601:133, 16:53:040601:1507, 16:53:040601:1510, 16:53:040601:1508, 16:53:040601:136, 16:53:040601:137 кадастр номерлы җир кишәрлекләре чикләрендә урнаштыру планлаштырыла.

4. Шәһәр паркы

Файдалануга тапшыру – 2032 ел.

Максат: шәһәрнең җитештерү һәм торак объектлары арасында буфер яшел зона булдыру юлы белән Түбән Кама шәһәренең экологик иминлеген һәм халыкның тормыш сыйфатын арттыру.

Объектларны 16:53:030103:23 кадастр номерлы җир кишәрлеге чикләрендә урнаштыру планлаштырыла.

Әлеге проектны Түбән Кама муниципаль районы чикләрендә 16:53:040601:133, 16:53:040601:1507, 16:53:040601:1510, 16:53:040601:1508, 16:30:011430:234, 16:30:011402:77, 16:53:030103:23, 16:30:011801:507, 16:30:011801:508, 16:30:011801:509, 16:30:011801:510 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә һәм җир кишәрлекләренең 16:30:011801 кадастр кварталыннан барлыкка килгән җир кишәрлекләрендә гамәлгә ашыру Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетлары, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән килешенгән.

16:30:011801:507, 16:30:011801:508, 16:30:011801:509, 16:30:011801:510 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендә һәм җир кишәрлекләренең 16:30:011801 кадастр кварталыннан барлыкка килгән җир кишәрлекләрендә «Этилен 600» индустриаль паркы объектларын урнаштыру өчен алынган урман фонды җирләре мәйданы 730,7814 гектардан да ким булмаячак.

Билгеләнгән чикләрдә «Этилен 600» индустриаль паркының 1.1. – 1.15. объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә, урман төзелеше документларына төзәтмәләр кертергә кирәк.

«Этилен 600» индустриаль паркы объектларын урнаштыру өчен, Түбән Кама муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертергә,

шулай ук тиешле муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелеше зоналаштыру документларына үзгәрешләр кертүне күздә тотарга.

Урман фонды җирләрен башка җир категорияләренә күчергәндә, гамәлдәге урман законнары таләпләрен үтәү кирәк. 2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Урман кодексының 62 статьясында киселгән, һәлак булган, зыян күргән урманнарны торгызу, шулай ук урманнарның файдалы функцияләрен, аларның биологик төрлелеген табигый, ясалма яки катнаш ысул белән саклау максатларында, урманнарны торгызу урманнарны торгызу проекты нигезендә урман утыртмаларын кисүне гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан гамәлгә ашыру каралган. Урманнарны торгызу кагыйдәләре, урманнарны торгызу проекты составы, урманнарны торгызу проектын эшләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибе Россия Табигать министрлыгының 2020 елның 4 декабрендәге 1014 номерлы боерыгы белән расланган.

Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буенча билгеләнгән «Түбән Кама» алгарышлы социаль-икътисади үсеш территориясе чикләренә төзәтмә кертү өчен проектны гамәлгә ашыру максатында, «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә кирәк.

2. Стратегиягә кушымтада:

Стратегиягә кушымтаның 1 бүлегендәге 1.1 пунктын әлеге үзгәрешләргә 1 нче кушымта нигезендә редакциядә 1.1.12 - 1.1.13 юллар белән тулыландырырга;

3 бүлекне әлеге үзгәрешләргә 2 нче кушымта буенча редакциядә 3.45-3.61 юллар белән тулыландырырга;

3.6, 3.8, 3.9, 3.11, 3.14, 3.17 пунктларның өченче баганасында «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының әйләнә-тирәлекне саклау бүлеге» сүзләрен «Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының хезмәт һәм әйләнә-тирәлекне саклау бүлеге» сүзләренә алыштырырга;

3.18, 3.19 пунктларның өченче баганасында «ТР Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш һәм архитектура идарәсе; ТР Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» сүзләрен «ТР Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре идарәсе һәм ТР Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» сүзләре белән алыштырырга;

3.20, 3.41, 3.42, 3.43 пунктларның өченче баганасында «ТР Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш һәм архитектура идарәсе» сүзләрен «ТР Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» сүзләренә алыштырырга.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.В. Умников

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 11 ноябрендәге 62 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясенә кертелә торган үзгәрешләргә
1 нче кушымта

| т/с | Төп чаралар исеме | Җаваплы башкаручы, башкаручылар | Гамәлгә ашыру чоры | Көтелгән нәтиҗәләр | Программа (ярдәмче программа) исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| 1.1.12 | «Этилен 600» индустриаль паркын гамәлгә ашыру | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы аерым икътисади зонасы» АҖ | 2024 -2032 еллар | Лаборатория-конструкторлык комплексы (гомуми мәйданы 1117 мең кв. метрлы «Алабуга Политех «Органик химия», «Синергия» индустриаль-технологик паркы корпуслары).<br>«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ җитештерүләре өчен логистик үзәк.<br>Социаль-белем бирү кластеры объектлары - белгечләр кампуслары (7 корпус).<br>Шәһәр паркы. | 2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2022 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлеге |
| 1.1.13 | «Корабельная роща» сәламәтләндерү үзәген реновацияләүне гамәлгә ашыру | «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ | 2022-2026 еллар | 16:30:010703:3, 16:30:010703:4, 16:30:000000:1158, 16:30:010703:6 кадастр | Инвестиция проекты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | номерлы җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан һәм «Олимпиец» спорт лагере астындагы территориядәге түбәндәге составта объектларны реновацияләү, гомуми мәйданы ~ 65 га:<br>1)«Корабельная роща» шифаханә-профилакторие (мәйданы 17,4 га);<br>2) «Юность» сәламәтләндерү лагере (мәйданы 30,5 га);<br>3) «Олимпиец» спорт лагере (мәйданы ~ 11 га);<br>4) футболистлар спорт базасы (мәйданы 1,3 га);<br>5) кунаклар комплексы (территория мәйданы 4,3 га) | |

Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 11 ноябрендәге 62 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының социаль-икътисади үсеш стратегиясенә кертелә торган үзгәрешләргә
2 нче кушымта

| т/с | Төп чаралар исеме | Җаваплы башкаручы, башкаручылар | Гамәлгә ашыру чоры | Көтелгән нәтиҗәләр | Программа (ярдәмче программа) исеме |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.45 | 8000 кв. м 1500 урынга Яшьләр үзәге төзелеше | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре идарәсе | 2030 елга кадәр | Түбән Кама муниципаль районы яшьләренең ялын оештыру өчен шартлар тудыру | Яшьләр үзәкләрен реконструкцияләү һәм реновацияләүнең республика программасы |
| 3.46 | «Камский Артек» үзәге» МБУга капиталь ремонтның өченче этабы | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре идарәсе | 2030 елга кадәр | Ел дәвамында балалар һәм яшүсмерләрнең ял итүе һәм үсеше өчен шартлар тудыру | ТР Яшьләр эшләре министрлыгының «Балаларга – җәй» программасы кысаларында |
| 3.47 | «Айда» ябык экстрим-парк төзелеше | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре идарәсе | 2030 елга кадәр | Түбән Кама муниципаль районы яшьләренең ялын оештыру өчен шартлар тудыру | «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты |
| 3.48 | «Доброволец» яшүсмерләр клубын капиталь ремонтлау | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре идарәсе | 2025 елга кадәр | Түбән Кама муниципаль районы яшьләренең ялын оештыру өчен шартлар тудыру | ТР яшүсмерләр клубларына капиталь ремонт республика программасы |
| 3.49 | 48 нче микрорайонда 300 урынга Прогимназия төзелеше | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2024-2025 еллар | Туган (татар) телдә укытуда дәвамчанлыкны тәэмин итү | Республика бюджеты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.50 | 51 нче микрорайонда 1224 урынга яңа мәктәп төзелеше | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе | 2024-2025 еллар | Җәяү йөрерлек арада мәктәптә урыннар белән тәэмин итү | Россия Федерациясенең «Мәгарифне үстерү» дәүләт программасы |
| 3.51 | 49 нчы микрорайонда 260 урынга мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе төзелеше | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәктәпкәчә белем бирү идарәсе | 2024-2025 еллар | Җәяү йөрерлек арада балалар бакчасында урыннар белән тәэмин итү | «Демография» илкүләм проекты |
| 3.52 | Балалар сәнгать мәктәбе төзелеше | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2024-2027 еллар | Өстәмә белем алу өчен шартлар тудыру:<br>- балаларны уңайлы заманча шартларда укыту;<br>- укучылар санын арттыру;<br>- лауреатлар һәм дипломантлар санын арттыру;<br>- яңа иҗат коллективлары булдыру | «Мәдәният» илкүләм проекты |
| 3.53 | Стахеевлар утарын реконструкцияләү | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе | 2024-2027 еллар | Тарихи мирасны саклау, республика әһәмиятендәге объектны торгызу. Мәдәни кыйммәтләрне саклау өчен уңайлы шартлар тудыру | «Мәдәният» илкүләм проекты<br>Инвесторлар акчаларын җәлеп итү хисабына |
| 3.54 | «Балалар медицина реабилитациясе үзәге» ДАССУны реконструкцияләү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсе, | 2023, 2024 еллар | Медицина хезмәтләре спектрын киңәйтү (нейрореабилитация, травматология), бронх-үпкә системасы һәм югары сулыш юллары, ашказаны-эчәк тракты, сидек куыгы-җенес системасы, нерв системасы, кан әйләнеше системасы, терәк-хәрәкәт | финанслау чыганагы билгеләнмәгән |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты | | аппараты авырулары белән тулы хокуклы торгызу процессын оештыру | |
| 3.55 | «Түбән Кама район үзәк күппрофильле хастаханәсе» ДАССУның «Бактериология лабораториясе» төзелеше | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсе, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты | 2024 ел | Кисәтмәләрне бозуны бетерү (чыг. № 13/36056, 26.10.2019) | финанслау чыганагы билгеләнмәгән |
| 3.56 | «Медицина реабилитациясе үзәге»н реконструкцияләү | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Түбән Кама муниципаль районы буенча Сәламәтлек саклау идарәсе, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты | 2026 ел | Үзәкне ачу Түбән Кама муниципаль районының өлкән яшьтәге халкына медицина ярдәме күрсәтүнең ябык циклын оештырырга, өзлегүләр санын киметергә, медицина оешмаларында дәвалану срокларын кыскартырга, халыкның үлем һәм инвалидлыгын киметергә, халыкның тормыш сыйфатын һәм канәгатьлеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк | финанслау чыганагы билгеләнмәгән |
| 3.57 | 15 нче микрорайонда 50 метрлык йөзү бассейны төзелеше | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт идарәсе | 2030 ел | Бердәм үткәрү сәләтен арттыру (200 к/сәг), физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүчеләрне арттыру | Программадан тыш проектлар; проект гамәлдә булуын дәвам иткәндә «Спорт - тормыш нормасы» федераль проекты |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3.58 | 1000 урынга Спорт сарае | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт идарәсе | 2028 ел | Бердәм уткәрү сәләтен арттыру (100 к/сәг), физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүчеләрне арттыру | Программадан тыш проектлар; проект гамәлдә булуын дәвам иткәндә «Спорт - тормыш нормасы» федераль проекты |
| 3.59 | Тынычлык проспектының Корабельная урамыннан М-7 трассасына кадәр дәвамы төзелеше | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе | 2030 елга кадәр | Федераль трассага уңайлы һәм куркынычсыз чыгуны тәэмин итү | Федераль һәм республика программалары |
| 3.60 | «СемьЯ» паркын төзекләндерү | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты | 2026 ел | Активлык һәм ял итү зоналары белән уңайлы шәһәр мохите булдыру | Федераль һәм республика программалары |
| 3.61 | Индустриаль парк төзелеше (16:53:010101:41 кадастр номеры) | Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе | 2030 елга кадәр | Җитештерү характерындагы предприятиеләрне үстерү өчен мәйданчык булдыру | финанслау чыганагы билгеләнмәгән |